СОВЕТ МАЙДАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ МӘЙДАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

09.04.2025 с. Майдан № 58-296

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 2, 4, 7.2 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы 26 статьясындагы 25, 7 өлеше, “Мәйдан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 31 статьясы, “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын бирү турында” 2025 елның 27 гыйнварындагы 11 номерлы Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясе карары нигезендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын һәм аның график сурәтен ун елга расларга (кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» 2020 елның 24 апрелендәге 68-315 номерлы Мәйдан авыл җирлеге Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгару юлы белән (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштыру юлы белән (https://verhniy-uslon.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан районының Мәйдан авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, Мәйдан ав. ,Киров,Яңа,Совет,Кооператив,Беренче Май,Яшьләр урамнары,Теньки урманчылыгы

һәм Урманчылык бистәләре, Ясная Звезда авылы, Урман урамы адреслары буенча, закон тарафыннан билгеләнгән срокларда халыкка җиткерергә.

4. Карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы В. В. Михеев

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Советының
09.04.2025 ел № 58-296 карарына
1 номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Советына депутатлар сайлау өчен бер мандатлы сайлау округлары схемасы

1нче номерлы Мәйдан бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны-45

Округка Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының “Мәйдан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Мәйдан авылы, Новая урамы, Киров урамы - 38 - 100 йорт, Кооператив урамы, 1-17 йортлар.

2нче номерлы Мәйдан бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны-35

Округка Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының “Мәйдан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Мәйдан ав., Совет урамы,1, 3, 4, 5, 10, 37, 41, 43, 45, 47, 49, 52 йортлар.

3нче номерлы Мәйдан бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны-43

Округка Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының “Мәйдан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Мәйдан авылы: Совет урамы, 2, 7, 9, йорт 11-15, йорт 17-33, Мәйдан авылы: Беренче Май урамы, 2, 4, 8, 10, 12, 19А, 21, 23, 25 йортлар

4нче номерлы Мәйдан бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны-41

Округка Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының “Мәйдан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Мәйдан авылы: Кооператив урамы, 18 дән 85 кә кадәр йортлар

5нче номерлы Мәйдан бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны-41

Округка Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының “Мәйдан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Мәйдан авылы: Киров урамы, 1дән 34 йортлар, Беренче Май урамы, 3, 5, 9, 11, 13, 14, 17, 18, 19, 22, 24 йортлары 28-70 (җөп ягы),

6нчы номерлы Мәйдан бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны-45

Яшьләр урамы, 1- 7нче йортлар, Яшьләр урамы, 9, 11нче йорт.


Тәмте-Урманчылыгы бермандатлы 7 нче сайлау округы

Сайлаучылар саны-39

Округка Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының “Мәйдан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Тәмте-Урманчылыгы бистәсе, Лесная урамы, 100 нче йорт.
Ясная Звезда авылы, Урман урамы

Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Советының
09.04.2025 ел № 58-296 карарына
2 номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Советына депутатлар сайлау өчен бер мандатлы сайлау округлары схемасының график сурәтләре





Ясная Звезда
17
Теньковского
лесничества